| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>ул.Советская дом 55А, село Лашманка, 423110 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ**<br>Советлар урамы,55А йорт, Лашман авылы, 423110 |
|---|---|---|

тел./факс +7(84396) 2-92-35 email: Lash.Cmn2@tatar.ru

**№ 109** **18 декабрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

«Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең 2013 елның 20 февралендәге № 62 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ, 2023 елның 10 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» № 286-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең 2013 елның 20 февралендәге №62 карарына (Советның 2018 елның 21 декабрендәге № 120; 2021 елның 30 сентябрендәге №38, 2021 елның 17 декабрендәге №44; 2023 елның 13 мартындагы №75, 2023 елның 27 июнендәге № 85 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «үз карамагындагы муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;».

1.2. 2.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәтенең кадрлар бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Р.Г.Фәттахов